# *Әтием - горурлыгым*

Гаиләдә иң зур кеше, баш кеше - әти. Чөнки ул гаиләнең барлык башка кешеләре турында кайгырта, җилдән, яңгырдан саклый, төрле авырлыклар килгәндә аларны яклый. Өйдәге иң авыр эшләрне дә әти эшли.



http://aida.ucoz.ru

# ИСЕМ

## БЕЛДЕРЕЛҮЕ

| предмет | зат |
| --- | --- |
| *яңгырдан* | *әтием* |
| *җилдән* | *кеше* |
| *өйдәге* | |



http://aida.ucoz.ru

# ИСЕМ

СОРАУЛАРЫ

Кем?

Нәрсә?



http://aida.ucoz.ru

Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор,
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр.  (Г.Тукай)

# Исем төркемчәләре

Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор,
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр.
(Г.Тукай)



http://aida.ucoz.ru

# ИСЕМ

## ТӨРКЕМЧӘСЕ

- ЯЛГЫЗЛЫК
- УРТАКЛЫК



http://aida.ucoz.ru

## Беренче төркемдәге сүзләр белән икенче төркем арасында нинди аерма бар?

1. Агач, урам, төн, бала, дәрес ,чирәм, таң, уенчык.
2. Агачлар, урамнар, төннәр, балалар, дәресләр, чирәмнәр,таңнар, уенчыклар



http://aida.ucoz.ru

# ИСЕМ

САНЫ

БЕРЛЕК

КҮПЛЕК



http://aida.ucoz.ru

# Физкультминут

Хәзер бераз ял итик
Тәнебезгә көч кертик
Бер урында таптаныйк,
Сикергәләп тә алыйк,
Уңга таба күз салыйк,
Сулга таба күз салыйк.
Муеннарны боргалыйк,
Ишкәкләрне нык ишик
Беләкләрне ныгытыйк,

Кулларны алга сузыйк,
Үткен кайчылар булыйк.
Бер чүгәлик, бер торыйк,
Кул тәгермәне ясыйк
Тиз армаска тырышыйк
Арганнарга булышыйк
Хәрәкәттә—бәрәкәт
Тәнгә сихәт, җанга — рәхәт
Хәрәкәттә мең рәхмәт!

# “Хатаны тап” уены

**1 нче төркем**

Б.к. әтигә
И.к. әтине
Ю.к. әтинең
Т.к. әти
Ч. к. әтидә
Ур. в. к. әтидән

**2 нче төркем**

Б.к. әнигә
И.к. әнине
Ю.к. әнинең
Т.к. әни
Ч. к. әнидә
Ур. в. к. әнидән



http://aida.ucoz.ru

# ИСЕМ






http://aida.ucoz.ru

# Кроссворд

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | к | ә | б | е | с | т | ә | | | |
| | | 2 | с | у | г | а | н | | | |
| | 3 | к | и | ш | е | р | | | | |
| | | | | 4 | | т | о | р | м | а |
| | | 5 | б | о | р | ы | ч | | | |
| | | | 6 | г | ө | м | б | ә | | |

1. Йөз кат кием, барысы да
   төймәсез.
2. Ормый сукмый,
   Үзе кешене елата.
3. Өсте яшел, асты кызыл,
   җирдә үсә.
4. Шалкан кебек йомры,
   Алма кебек кызыл.
5. Ашка салсаң, тәм кертә,
   Борынга салсаң, төчкертә.
6. Утырабыз урманда
   Ап-ак эшләпә киеп.
   Киптерә дә, кыздыра да
   Кешеләр безне җыеп.

# ИСЕМ

## ТАРТЫМ

| I зат | II зат | III зат |
|---|---|---|
| -ым/ -ем<br>-ыбыз/ -ебез | -ың/ -ең<br>-ыгыз/ -егез | -ы/ -е<br>-сы/ -се<br>-лары/ -ләре |



http://aida.ucoz.ru

## Түбәндә бирелгән җөмләләрдә исемнәрнең ясалышы ягыннан нинди төрләре бар?

**Әни** өйдә булганда, һәрвакыт рәхәт.

Ана - тормышның бөек **юлдашы**.

**Дәү әниләр** сүзенә колак салырга кирәк.

Аның  әтисенең исеме – **Иргали**.

Укытучы иртәгә **әти-әниләрне** җыелышка чакырды.



http://aida.ucoz.ru

# ИСЕМ






http://aida.ucoz.ru

**Түбәндәге шигырьләрдән исемнәрне табыгыз, аларның җөмләдәге функциясен билгеләгез**

1. Тал буенда үскән камышлар да
   Бер-беренә серен сөйләми.
   Тишелгәндер, ахыры, күкнең төбе,
   Сибәли дә, яңгыр сибәли.
   *(“Күзге моңсулык” М. Максиев)*
2. Гомерлеккә килмәгәнбез,
   Без җирдә кунак кына. *(М. Максиев)*



http://aida.ucoz.ru

# Исемнең җөмләдәге функциясе

Тал буенда үскән камышлар да
Бер-беренә серен сөйләми.

Тишелгәндер, ахыры, күкнең төбе,
Сибәли дә, яңгыр сибәли.

Гомерлеккә килмәгәнбез,
Без бу җирдә кунак кына.



*("Көзге моңсулык" М. Максиев)*

http://aida.ucoz.ru

# ИСЕМ

## ҖӨМЛӘДӘГЕ ФУНКЦИЯСЕ

**баш кисәкләр**

ия
хәбәр

**иярчен кисәкләр**

аергыч
тәмамлык
хәл



http://aida.ucoz.ru

# Исемнең моделе

## ИСЕМ

**ЯЛГЫЗЛЫК** | **УРТАКЛЫК**

| БЕЛДЕРӘ | СОРАУЛАРЫ | ТӨРЛӘНЕШЕ | ЯСАЛЫШЫ | ФУНКЦИЯСЕ |
|---|---|---|---|---|
| предмет, затны | кем? нәрсә? | килеш<br>сан<br>тартым | тамыр<br>ясалма<br>кушма<br>парлы<br>тезмә<br>кыскартылма | ия<br>хәбәр<br>аергыч<br>тәмамлык<br>хәл |



http://aida.ucoz.ru

# Дөрес җавапны сайла

1. а) Исем нинди? кайсы? соравына җавап бирүче сүз төркеме.
   *б)*Исем кем? нәрсә? соравына җавап бирүче сүз төркеме.
2. *а)* Ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла.
   *б)* Ялгызлык исемнәр юл хәрефтән языла.
3. *а)* Бары килеш белән төрләнә.
   *б)* Тартым, килеш, сан белән төрләнәләр.
4. *а)* Татар телендә 6 килеш бар.
   *б)* Татар телендә 5 килеш бар.
5. *а)* Ясалышы ягыннан *аккош* тезмә исем.
   *б)* Ясалышы ягыннан *аккош* кушма исем.
6. **Икесе дә безнең өчен иң кирәкле затлы тел.**
   *а)*Бу җөмләдә исем хәбәр булып килгән.
   *б)*Бу җөмләдә исем ия булып килгән.

# Тестның ачкычы

1.Б

2.А

3.Б

4.А

5.Б

6.Б





http://aida.ucoz.ru

# Белемнәрегезне бәяләгез

| | |
|---|---|
| 0 - 1 | “5” |
| 2 - | “4” |
| 3 - | “3” |
| 4 - 6 | “2” |



http://aida.ucoz.ru

# Өй эше

1. Модель буенча исем сүз төркеме турында сөйли белергә.
2. Исемнәрне кулланып "Минем гаиләм" дигән темага кечкенә инша язып килергә.



http://aida.ucoz.ru

# Рефлексия

1. Дәрестә нинди тема кабатладык?
2. Максатка ирештекме?
3. Киләсе дәрестә нишләрбез?



http://aida.ucoz.ru